**МИНИСТЕРСТВО ЗДРАВООХРАНЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**25.04.2018** г. Казань № **929**

Белгечне максатчан хәзерләү һәм эшкә
урнаштыру турында дүртьяклы килешүнең
типлаштырылган формасын раслау турында

2015 елның 2 февраленнән № 137-р Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсенең 2 пунктын үтәү йөзеннән, б о е р а м:

1. Белгечне максатчан хәзерләү һәм эшкә урнаштыру турында дүртьяклы килешүнең типлаштырылган формасын расларга.
2. Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләренең җитәкчеләренә һәм медицина көллиятләренең һәм училищеларының директорларына Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының юнәлешләре буенча белгечне максатчан хәзерләү һәм эшкә урнаштыру турында дүртьяклы килешүләрне төзү буенча эшне оештырырга.
3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Медицина эшчәнлеге стандартларын һәм сыйфатын тикшерү идарәсенең медицина белемен бирү һәм аттестацияләү бүлегенең башлыгына Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының бюджет максатчан урыннарына булган конкурста абитуриентларның алга таба катнашулары өчен медицина көллиятләренә һәм училищеларына юлламалар бирүне оештырырга.
4. 2018 елның 1 июненнән башлап әлеге боерык үз көченә керә дип билгеләргә.
5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры урынбасары И. Р.Фатыйховка йөкләргә.

Министр М.Н.Садыйков

Ванюшина Т. В.
8(843) 231-79-18

25.04.2018 № 929
ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы боерыгы белән расланган

**Белгечне максатчан хәзерләү һәм эшкә урнаштыру турында дүртьяклы килешүнең ТИПЛАШТЫРЫЛГАН ФОРМАСЫ**

Казан шәһ. "___"___________ 20__ г.

Бер яктан, Нигезләмә нигезендә гамәлдә булучы, алга таба «Заказ бирүче» дип аталучы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы _____________________________________________йөзендә,
икенче яктан, Устав нигезендә гамәлдә булучы, алга таба «Медицина оешмасы» дип аталучы сәламәтлек саклау учреждениесе

_____________________________________________,
*(тулы атамасы)*
җитәкчесе йөзендә
_____________________________________________,
*(вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)*
өченче яктан, Устав нигезендә гамәлдә булучы, алга таба «Белем бирү оешмасы» дип аталучы Татарстан Республикасының дәүләт автономияле һөнәри белем бирү учреждениесе
_____________________________________________,
*(тулы атамасы)*
җитәкчесе йөзендә
_____________________________________________,
*(вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)*
һәм дүртенче яктан, алга таба «Гражданин» дип аталучы, _____________________________________нигезендә гамәлдә булучы,
*документ – нигезләмә (реквизитлары)*
максатчан укытуга кабул ителүче шәхес,
_____________________________________________,
*(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)*
«____»________________ елда туган, законлы вәкиле йөзендә

_____________________________________________,
*(балигъ булмаган шәхеснең законлы вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта))*
бергә «Яклар» дип аталучы, әлеге килешүне төзеделәр, алга таба «Килешү» дип аталучы, түбәндәге турында:

## 1. Килешү предметы

Яклар, Гражданин мәнфәгатьләрен исәпкә алып, Заказ бирүченең һәм Медицина оешмасының урта медицина белеме белән белгечләрендә ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен _____________________________________________
*(урта һөнәри белем бирүнең һәм квалификациянең атамасы һәм белгечлегенең яки юнәлешенең номеры)* (алга таба белгечлек) буенча белгечнең максатчан контрактлы хәзерләвен тормышка ашырырга үз өсләренә бурычлар кабул итәләр.

## 2. Якларның хокуклары һәм бурычлары.

2.1.1.Заказ бирүче хокуклы:

а) Белем бирү оешмасында укучы Гражданинның өлгерешенә күзәтү үткәрергә;

б) Белем бирү оешмасы тарафыннан оештырылган урта медицина персоналын хәзерләүнең һәм квалификациясен күтәрүнең системасын камилләштерү проблемалары буенча укыту-методик һәм фәнни чараларда катнашырга.

2.1.2.Заказ бирүче бурычлы:

а) Россия Федерациясендә билгеләнгән алган белгечлегенә, квалификациясенә һәм һөнәри эшчәнлеккә керү хокукына туры китереп, максатчан контрактлы хәзерләү тәртибендә укучы Гражданинга Медицина оешмасында эш урыны тәэмин итәргә;

2.2.1. Белем бирү оешмасы хокуклы:

а) әлеге Килешү белән каралган очракларда Гражданиннан аны укытуга киткән чыгымнарны каплауны таләп итәргә.

2.2.2. Белем бирү оешмасы бурычлы:

а) Гражданин белгечлек буенча белем бирү программасын үзләштерсен өчен, дәүләт белем бирү стандартына туры китереп, кирәкле шартларны тәэмин итәргә;

б) һәр елның уку елы тәмамланганнан соң 1 сентябренә кадәр Гражданинның киләсе курска күчерелүе турында белдерүче документны Медицина оешмасына бирергә (киләсе курска күчерелүе турында Белем бирү оешмасы боерыгының күчермәсен (өземтәсен) һ.б.);

в) Гражданин белгечлек буенча белем бирү программасы белән каралган бөтен уку фәннәрен һәм һөнәри модульләрне уңышлы үзләштерү очрагында, дәүләт йомгаклау аттестациясен узуны, йомгаклау аттестациясе уңышлы узганнан соң белем бирү турындагы документларны бирүне тәэмин итәргә;

г) Гражданин тарафыннан  белем бирү программасының таләпләрен үтәмәве, аның башка белем бирү программасы буенча укуга күчерелүе, укудан чыгарылуы турында, шулай ук әлеге Килешүне үтәү өчен мәгънәсе булган башка шартлар турында Заказ бирүчегә  шул шарт барлыкка килгән вакыттан башлап 10 календарь көне эчендә язмача рәвештә белдерергә;

д) белгечлек буенча практиканың (алга таба - практика) төп һөнәри белем бирү программасы белән каралган практиканың барлык төрләрен: укыту, җитештерү, диплом алды практикасын үтү өчен Гражданинга Медицина оешмасына юллама тәэмин итәргә;

е) Гражданин Белем бирү оешмасында укуны тәмамлаганнан соң, белем бирү турында документны алганнан соң 10 көн эчендә Заказ бирүчегә бу хактагы мәгълүматны тапшырырга (Белем бирү оешмасын тәмамлау турында боерыкның, белем бирү турында документ бирелүнең күчермәсен (өземтәсен) һ.б.).

2.3.1.Медицина оешмасы хокуклы:

а) Практика узган вакытта Медицина оешмасының эчке хезмәт тәртибенең кагыйдәләрен Гражданин тарафыннан үтәүне таләп итү.

2.3.2.Медицина оешмасы бурычлы:

а) Гражданинның уку планына һәм дәресләр расписаниесенә туры китереп, практиканың барлык төрләрен узуны тәэмин итәргә, булачак эш урыны һәм үзенчәлекләре белән таныштырырга;

б) максатчан контрактлы хәзерләү тәртибендә укучы Гражданинга Россия Федерациясендә билгеләнгән, алган белгечлегенә, квалификациясенә һәм һөнәри эшчәнлеккә керү хокукына туры китереп, Медицина оешмасында эш урыны белән тәэмин итәргә;

в) Килешү белән билгеләнгән вакыт эчендә хезмәт килешүен (контрактын) төзү өчен Гражданинның Медицина оешмасына килмәве очрагында, Заказ бирүчегә һәм Белем бирү оешмасына 10 көн эчендә хәбәр итәргә.

2.4.1. Гражданин хокуклы:

а) белем бирү турындагы законнар белән каралган стипендия, башка түләүләр алырга;

б) Гражданин законнар җыелмасы белән каралган башка хокукларга ия.

2.4.2. Гражданин бурычлы:

а) белгечлеге буенча белем бирү программасын үзләштерергә;

б) Белем бирү оешмасында укуны тәмамлаганнан соң һәм белем бирү турында документны алганнан соң 30 көн эчендә Медицина оешмасының карамагына килергә һәм 3 елдан да ким түгел Медицина оешмасында эшләргә;

в) Белем бирү оешмасында укуны тәмамлаганнан соң өч ел узгач, 1 августка кадәр Заказ бирүчегә хезмәт кенәгәсенең күчермәсен тапшырырга;

г) Килешү белән каралган очракларда укытуга киткән чыгымнарны Белем бирү оешмасына капларга;

д) медицина югары белем бирү оешмасына керү турында, Россия Федерациясенең Кораллы көчләрендә хәрби хезмәткә чакырылу турында Заказ бирүчегә, Медицина оешмасына һәм Белем бирү оешмасына укуга керү яки хәрби хезмәткә чакырылу вакытыннан башлап 15 календарь көне эчендә хәбәр итәргә.

2.5. Килешүнең 2.4.2. пунктының «б» подпунктында күрсәтелгән эшләп бетерү срогы Россия Федерациясенең Кораллы көчләренә чакырылу буенча хезмәт итү вакытына, бала тәрбияләү буенча ял вакытына озынайтыла, бу турыда әлеге килешүгә өстәмә килешү төзелә. Россия Федерациясе Кораллы көчләренең медик-санитар бүлегендә хезмәт итү вакыты Килешүнең 2.4.2. пунктының «б» подпунктында күрсәтелгән эшләп бетерү срогы хисабына кертелә.

## 3. Якларның җаваплылыгы

3.1. Яклар әлеге Килешүнең шартларын үтәмәү яисә тиешенчә үтәмәү өчен Законнар җыелмасына туры китереп җаваплылык тоталар.

3.2. Гражданин аны укытуга киткән чыгымнарны Белем бирү оешмасына бер ай эчендә тулысынча каплый түбәндәге очракларда:

а) академик өлгермәгәнлеге, укыту дисциплинасын, хезмәт тәртибенең эчке кагыйдәләрен бозу өчен Белем бирү оешмалары инициативасы буенча Гражданинны укудан чыгару;

б) Нигезле сәбәпләрдән башка үз теләге буенча Гражданинны Белем бирү оешмасыннан чыгару;

в) әгәр Белем бирү оешмасында укуны тәмамлаганнан соң Гражданин әлеге Килешү буенча булган бурычларны үтәмәсә, Медицина оешмасы белән хезмәт килешүе төзүдән баш тартса, Медицина оешмасында эшкә керешмәсә.

3.3. Гражданин аны укытуга Белем бирү оешмасының чыгымнарын каплау буенча бурычларын үтәүне раслау өчен, түләү көненнән соң киләсе көннән соңга калмыйча, Заказ бирүчегә, Белем бирү оешмасына һәм Медицина оешмасына түләү турында түләү документының оригиналы белән күчермәсен тапшыра, шуннан соң Яклар тарафыннан Килешүне өзү турындагы Килүшегә кул куела.

3.4. Гражданин үзенең язмача гаризасы буенча эшкә урнашу буенча бурычларын үтәүдән түбәндәге очракларда (Килешү төзегәннән соң барлыкка килгән) азат ителә:

а) билгеләнгән тәртиптә медицина нәтиҗәләре белән расланган, әлеге Килешү белән бәйләнгән, эшне башкару өчен зарарлыкны күрсәтә торган медицина билгеләре булганда;

б) югары медицина белеме бирү оешмасына укытуга кабул иткәндә;

в) ата-ананың берсен, ирен (хатынын) I яки II төркем инвалиды итеп тану, гражданин баласына «бала-инвалид» категориясе билгеләү, әгәр хезмәт килешүе (контракты) буенча эш ата-аналарның, иренең (хатынының) яки баланың яшәү урыны буенча бирелмәсә;

г) гражданин хәрби хезмәткәрнең ире (хатыны) булып тора, хәрби хезмәтне чакыру буенча узучы шәхесләрдән тыш, әгәр хезмәт килешүе (контракты) буенча эш иренең (хатынының) хезмәт урыны буенча бирелмәсә;

д) Белем бирү оешмасында укуны тәмамлау һәм белем бирү турындагы документны алу вакытына йөкле булу яки балага өч яшь тулмау, әгәр Медицина оешмасы ире (хатыны) яки ата-аналары гаиләсенең даими тору урыныннан читтә урнашкан булса;

е) күрсәтелгән оешмаларның үтенеч гаризасы булган очракта Гражданинны әлеге Килешү белән каралмаган, башка эшкә: Татарстан Республикасы территориясендәге дәүләт медицина

оешмасына, шулай ук медик-социаль экспертиза оешмасына, хәрби комиссариатына һәм башка дәүләт оешмаларына эшкә урнаштыру.

**4. Бәхәсләрне чишү.**

4.1. Әлеге Килешүне башкарганда килеп чыгарга мөмкин булган бөтен бәхәсләр Яклар тарафыннан мөмкин булганча сөйләшүләр юлы белән судка кадәр тәртиптә чишеләчәкләр. Бәхәсне сөйләшүләр ярдәмендә җайга салу мөмкинлеге булмаганда бәхәс суд тәртибендә чишелә.

4.2. Гражданинның әлеге Килешүнең 3.2. пункты белән каралган аны укытуга киткән чыгымнарны капларга баш тартуы очрагында Белем бирү оешмасы суд тәртибендә бу чыгымнарны түләттерү буенча чаралар кабул итә.

**5. Башка шартлар.**

5.1. Әлеге Килешү Яклар белән кул кую вакытыннан башлап үз көченә керә һәм Яклар белән бурычларны тулысынча үтәлүгә кадәр гамәлдә була.

5.2. Әлеге Килешү Якларның язмача килешүе буенча яки суд тәртибендә үзгәртелергә, өзелергә мөмкин.

5.3. Әлеге Килешү дүрт нөсхәдә төзелде, һәр Як өчен берәр нөсхә.

**6. Якларның адреслары, реквизитлары, имзалары.**

**Заказ бирүче**

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы
Урнашкан урыны: 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһ., Островский ур., 11/6 йорт
Фактик адрес: 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһ., Островский ур., 11/6 йорт
Тел., факс, e-mail____________________

____________
*вазыйфасы*
______________________/______________
*имзасы* *ФИО*
"___"_______________________ 20__ г.
Баш бухгалтер
______________________/______________
*имзасы* *ФИО*
"___"_______________________ 20__ г.

**Белем бирү оешмасы**

________________________________________
________________________________________
*атамасы*
Урнашкан урыны:________________________
________________________________________
Фактик адрес:___________________________
Тел., факс, e-mail______________________

Җитәкче________________________
*вазыйфасы*
______________________/_________________
*имзасы* *ФИО*
"___"_______________________ 20__ г.

**Медицина оешмасы**

________________________________________
*атамасы*
Урнашкан урыны:
________________________________________
Фактик адрес:___________________________

**Гражданин (18 лет яшь тулмаган гражданинның законлы вәкиле)**

________________________________________
*фамилиясе, инициаллары*
паспорт: серия_________ №________________
________________________________бирелгән
*кем белән, кайчан*

| | |
|---|---|
| Тел., факс, e-mail ______________________ | Яшәү урынының адресы |
| | прописка буенча_______________________ |
| Җитәкче ____________________________ | фактик________________________________ |
| *вазыйфасы* | Телефон:_______________________________ |
| _________________/___________________ | _________________/____________________ |
| *имзасы* *ФИО* | *имзасы* *ФИО* |
| «____»__________________ 20__г. | «_____»_______________________ 20___г. |
| . | |
| . | |